ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

17.01.2025 — с. Набережные Моркваши — 1

«Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында»

«Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 29.10.2024 елгы 365 — ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә эш вакыты нормасын үтәгән хезмәткәрләргә билгеләнгән минималь хезмәт хакыннан 22440 сум күләмендә түбән булмаган хезмәт хакы түләүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе К.Г.Саттарова